РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Шингальчинского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

423554, Нижнекамский район,
с. Шингальчи, ул.Школьная, 6

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районының
Шәңгәлче авыл җирлеге
Башкармакомитеты

423554, Түбән Кама районы,
Шәңгәлче авылы, Мәктәп урамы,6

тел./факс (8555) 43-04-50, электронный адрес: Shingalchinskoe.Sp@tatar.ru, сайт: www.shingalchinskoe-sp.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

04.02.2020 ел № 11

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Шәңгәлче авыл җирлеге башкарма комитетының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Шәңгәлче авыл җирлеге Уставының 62 статьясы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советының 2020 елның 3 февралендәге 3 номерлы «Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетына Түбән Кама муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләренең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында килешүләрне раслау хакында» карарын игътибарга алып, карар бирәм:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Шәңгәлче авыл җирлеге башкарма комитеты карарлары:

«Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Шәңгәлче авыл җирлегендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2012 елның 18 июлендәге 44 номерлы карары;

«Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Шәңгәлче авыл җирлеге муниципаль хезмәтләр реестрын формалаштыру һәм алып бару турында Нигезләмәне раслау хакында» 2012 елның 17 июлендәге 43 номерлы карары;

«Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Шәңгәлче авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан күчемсез милек объектларына муниципаль милек реестрыннан өземтә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең

административ регламентын раслау турында» 2013 елның 15 гыйнварндәге 1-7 номерлы карары;

«Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Шәңгәлче авыл җирлегенең муниципаль милкен арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 15 гыйнварндәге 1-2 номерлы карары;

«Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Шәңгәлче авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан социаль наем шартнамәсе буенча торак бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 15 гыйнварндәге 1-12 номерлы карары;

«Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Шәңгәлче авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан архив белешмәләрен, архив өземтәләрен, архив документларының күчермәләрен бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 15 гыйнварндәге 1-1номерлы карары;

«Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Шәңгәлче авыл җирлегенең муниципаль милкен арендалау шартнамәсенә үзгәрешләр кертү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 15 гыйнварндәге 1-10 номерлы карары;

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм Шәңгәлче авыл җирлеге сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Р.Х. Салимов